**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА ПСЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423646 Республика Татарстан, Менделеевский район, д.Псеево ул. Центральная, д.4

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЕСӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

423646 Татарстан Республикасы, Менделеевск районы, Песәй авылы, Үзәк урам,4 йорт

Тел. (факс): (85549) 3-71-22 e-mail: Psv.Men@tatar.ru


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

1 ноябрь 2025 ел № 5

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Тукай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Уставының 22 ст. нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы “Песәй авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елның 13 ноябре 12.00 сәг. Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Тукай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә. Җыен уздыру урыны итеп Тукай авылы, Урман урамы, 15 йортны билгеләргә.
2. Гражданнар җыенында түбәндәге сорауны расларга:

« 2026 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Тукай авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, тыл ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, балигъ булмаган күп балалы гаиләләрдән, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан, Россия Армиясенә сроклы хезмәткә чакырылган гражданнардан 500 сум күләмендә, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын азат итеп, кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә:

«1) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Тукай авылындагы юлларны кардан чистарту)

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм www Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http:///mendsleevsk.tatarstan.ru “Песәй авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Песәй авыл җирлеге башлыгы ____________ В.И.Мөхәммәтгалеев
(имза) (имзаны киңәйтү)